Чыганак: Мәгариф.- 2013.- № 1.

# «МЕНӘ СИҢА, МӘ!»

(Г.Бәшировның шул исемдәге хикәясен өйрәнү дәресе)

**Чулпан ГАБДЕЛГАНИЕВА, Балтач районы Балтач гимназиясенең I квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

**Тәнкыйди фикерләүне үстерү технологиясе XX гасырда Америкада барлыкка килгән, дип исәпләнелә. Безнең илдә әлеге технология туксанынчы еллар уртасында гамәлгә керә башлый. «Критик» фикерләү, беренче карашка, «тәнкыйди фикер йөртү, тәнкыйть күзлегеннән карау» дип кабул ителә, ләкин белем бирү системасында бу төшенчә стандарт булмаган фикерләүне, укытуның иң югары дәрәҗәдә камилләшүен аңлата.**

**Мәгълүматны анализлый, мөстәкыйль рәвештә нәтиҗәләр ясый, кабул иткән карарларының киләчәген фаразлый һәм алар өчен җавап бирә ала торган кеше — тәнкыйди фикерләү сәләтенә ия булган кеше. Педагогик күзлектән чыгып, критик фикерләүне танып белүнең актив, иҗади процессы дип карарга мөмкин. Әлеге технология укытучыга хезмәттәшлек атмосферасы тудырырга, проблеманы чишү ысулларын бергә эзләргә мөмкинлек бирә торган нәтиҗәле алым һәм методларны тәкъдим итә.**

**Мин үз эшемдә тәнкыйди фикерләүне үстерү технологиясенең метод һәм алымнарын даими файдаланам. Яңа буын стандартларына күчү чорында бу технологияне өйрәнү зарури, дип саныйм, чөнки аның буенча эшләгәндә файдаланыла торган метод, алымнар стандарт куя торган бурычларны хәл итәргә булыша. Тәнкыйди фикерләүне үстерү технологиясенә нигезләнгән бер дәрес үрнәген журнал укучылар игътибарына тәкъдим итәм.**

**Максат:**

— Г.Бәшировның «Менә сиңа, мә!» хикәясе белән таныштыру;

— укучыларның тәнкыйди фикерләү сәләтен, әсәргә анализ ясау күнекмәләрен, бәйләнешле сөйләмен үстерү;

— әхлак сыйфатлары тәрбияләү; җитди карарлар кабул иткәндә аек акыл белән эш итәргә кирәклеген төшендерү.

**Дәрес тибы:** яңа белем һәм күнекмәләр формалаштыру дәресе.

**Метод һәм алымнар:** акылга «һөҗүм итү» («мозговая атака»), тукталышлар ясап уку (чтение с остановками), сүзлек эше, Блум сораулары, 5 минутлык эссе һ.б.

**Материал һәм җиһазлар:** Г.Бәшировның «Менә сиңа, мә!» хикәясе *(алдан ук укытучы өлешләргә бүлеп куя)*, китаплар күргәзмәсе *(мөстәкыйль укырга тәкъдим ителә торган әсәрләр)*, «Новые педагогические технологии в школьной библиотеке: образовательная технология развития критического мышления средствами чтения и письма» (И.Загашев. Интернет-лекцияләр); техник чаралар.

**Дәрес барышы.**

**I. Оештыру өлеше.**

**1. Сыйныфта уңай психологик халәт булдыру.**

**2. Дәрес темасына кызыксыну уяту.**

— Бүгенге дәресне шәхси сораудан башлыйсым килә: син көнчеме? Синеңчә, көнчелек — ул гөнаһмы? *(Җаваплар тыңлана.)*

**II. Теманы аңларга әзерләү.**

Акылга «һөҗүм итү» *(экранда кагыйдәләр язылган слайд чыга).*

**1 нче слайд:**

✓ фикерләрне кабатламаска;

✓ фикерне тәнкыйтьләмәскә һәм бәяләмәскә;

✓ мәсьәләгә төрле яклап якын килергә.

— Ә хәзер һәрберегез менә бу сорауга берничә җавап әзерләгез: «Сезнеңчә, нинди эш-гамәлләр гөнаһ була?» *(Сорау язылган ватман эленә, җаваплар язылып барыла.)*

— Әйтелгәннәрне нинди төркемнәргә аерып идегез? *(Кешенең үзенә, әйләнә-тирәдәгеләргә зыян сала торган эш-гамәлләр.)*

— Димәк, гөнаһ дип нәрсәне атап була? *(Үзеңә һәм башкаларга зыян сала торган гамәлләрне.)*

**III. Г.Бәшировның «Менә сиңа, мә!» хикәясе белән танышу.** *(Фикерләү. Тукталыш ясап уку методы.)*

**1. Әңгәмә.**

— Хәзер без Г.Бәшировның «Менә сиңа, мә!» хикәясе белән таныша башларбыз. Хикәянең исеменнән чыгып, сүзнең нәрсә турында барачагын фаразлап карыйк. *(Җаваплар тыңлана.)*

— Хикәядә кешеләргә хас булган нинди гөнаһлар телгә алына? Уку барышында шул хактагы җөмләләрне билгеләп барырсыз. Шулай ук аңлашылмаган сүзләрне дә тамгалап куярсыз.

**2. 1 нче өлешне уку.**

Укыганнан соң башкарыла торган эш төрләре.

А. Сүзлек эше.

**2 нче слайд:** *ямансу, ансат, аяктан ега язу.*

Ә. Сораулар:
— Мәфтуха карчык нинди кайгы кичергән?
— Ул ире белән ничек яшәгән?
— Ничек уйлыйсыз, Мәфтуха карчыкны «аяктан ега язарлык» нинди хәл була? *(Сорауларга, үз фикерләренә һәм әсәрдән алынган цитаталарга таянып җавап бирәләр.)*

**3. 2 нче өлешне уку.**
А. Сүзлек эше.
**3 нче слайд:** *ачык күзле кеше, көяз, каракүл бүрек, аллы-кызыллы Кукмара итеге, унбиш телле гармун, яшерен-батырын түгел, озын телләр.*
Ә. Сорау:
— Ни өчен озын телләр Мәфтухага: «Бармы җаның, юкмы? Ник Галәвиеңә күз-колак булмыйсың?» дигән «киңәш» бирәләр?

● **Физкультминут.**
Энергизатор. «Урын алышу».

**4. 3 нче өлешне уку.**
А. Сүзлек эше.
**4 нче слайд:** *очырма, карындык, сөяркә, гарьлегеннән, йөзлек буенда атына-атына елады, шәригать, нәмәхрәм.*
Ә. Сораулар:
— Мәфтуханы аяктан егарлык нинди хәл була?
— Карчыкның күңеленә килгән сорауларга игътибар итегез. Ул нинди нәтиҗә ясый? *(«Кемнәр белән себерелгән бит!»)*
— Монда нинди җөмләләр өстенлек итә? *(Сорау, тойгылы.)*
— Карчык нәтиҗәне нәрсәгә нигезләнеп ясый? *(Шик.)*
— Мәфтуха әби ни өчен елый? *(«Хурлыгыннан», «гарьлегеннән», «оят».)*
— Ул ни өчен гарьләнә? *(Үзе гомере буе тугры булган. Шәригатькә, татар халкының яшәү рәвешенә, әдәп-әхлакка каршы килә торган гамәлләр башкарылудан курка.)*
— Ничек уйлыйсыз, Мәфтуха карчык табылган дәфтәр белән нишләр?

**5. 4 нче өлешне уку.**
А. Сүзлек эше.
**5 нче слайд:** *бәддога, никахлы зәүҗәсенә, әйле-шәйле килү, бүрәнә аркылы бүре күрү.*
Ә. Сораулар:
— Бу өлештә *шик* сүзе янә килеп керде. Мәфтуха түти хәзер нәрсәдән шикләнә?
— Киңәш сорап, ул кемгә мөрәҗәгать итә? Ни өчен мөгаллимне сайлый?
— Әсәрдә мөгаллимнең исеме әһәмиятле түгел дигән хис калды миндә, сезгә дә шулай тоелмадымы? Моны ничек аңлатып була? *(Мөгаллимнең авыл кешесе алдындагы дәрәҗәсе белән.)*
— Киңәш өчен мөгаллимне сайлау белән килешәсезме? Укытучы үзен ничек тота? *(«Сак», «шик-шөбһә тудырмаслык...»)*
— Чынлыкта Галәви нәрсә язды икән, ничек уйлыйсыз?

**6. 5 нче өлешне уку.**
А. Сүзлек эше.
**6 нчы слайд:** *риясыз, зиһен чуалу.*
Ә. Сораулар:
— Карчык, балаларына карап, нәрсә уйлады?
— Ире турында әйтергә җыенган сүзләрен автор ничек атый? *(Усал сүзләр.)*
— Ни өчен Мәфтуха ирен фаш итмәде? *(«Гомерләре буена кара тап булып каласы икән».)*
— Сез бу сүзләрне ничек аңлыйсыз? *(Хурлык үзенә һәм нәселенә төшәчәк.)*
— Карчык ахыр чиктә нәрсәгә таянды? *(Акылга.)*
— Ирен фаш итсә, Мәфтуханың «өстеннән тау төшкәндәй» булыр идеме? Ул кемгә зыян салыр иде?
— М.Әгъләмовның «Бары шул» шигыренә игътибар итегез. Бу шигырьне кемгә киңәш рәвешендә укыр идегез?

**7 нче слайд.**

**Бары шул**

Кешенең кешене җиңәсе килә:
Дошманны буасы,
Дусларын узасы,
һәр җирдә, һәркайда
Беренче буласы.
Әгәр дә иң башта
Акылның җиңүе
Ләззәтен белмәсә,
Тукталып уйларга
Тапмаса агымсу,
Ул бетә.
Бары шул.

*М.Әгъләмов*

**IV. Рефлексия.**
**1. Әңгәмә.**
— Әсәрне уку барышында сез гөнаһ турындагы җөмләләрне билгеләп бардыгыз. Хикәядә кешегә хас нинди гөнаһлар телгә алына? *(Зина кылу, көнчелек, үч алу теләге, гайбәт сөйләү, нахак сүз сөйләү, кешене каргау...)*
— Алар нәрсәгә китерә? *(Кешегә гомере буена кара тап ягыла.)*

**2. Эссе язу** *(кагыйдәләре экранда).*
**8 нче слайд:**
√ язганны төзәтмәскә;
√ тема буенча башка ни килә, барысын язарга;
√ кабат укымаска;
— Хәзер үзегез гөнаһ дип санаган бер гамәлне тема итеп язып куегыз һәм шул турыда үз фикерләрегезне белдереп языгыз. *(Кагыйдәләр искәртелә. Эссе язу өчен 5 минут вакыт бирелүе әйтелә.)*

**3. Берничә эшне укыту, дәфтәрләрне җыю.**

**V. Йомгаклау.**
— Бүген без сөйләшкән тема татар әдәбиятында күп әсәрләрдә чагылыш таба. Мин сезгә кайберләрен укырга киңәш итәм. *(Әсәрләр исеме әйтелә: М.Гафури. «Кара йөзләр», Ә.Еники. «Саз чәчәге»...)*
**Өйгә эш.** Әсәрдән тел-сурәтләү чараларын табарга *(көчле укучыларга)*; Мәфтуха образына характеристика бирергә *(башка укучыларга).*